МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**22.03.2018** г. Казань № **592**

Казан шәһ.

Хәрби һәм аңа тиңләштерелгән хезмәт вазыйфаларын башкару уңае белән махсус исемнәргә ия булучы аерым категориянең гражданнарына күрсәтелгән медицина ярдәме кыйммәтенең тарифы турында

2016 елның 5 апрелленнән № 157 «Россия Федерациясе милли гвардиясенең Федераль хезмәте гаскәрләренең мәсьәләләре» Россия Федерациясе Президентының указын, 2004 елның 31 декабреннән № 911 «Хәрби хезмәткәрләрнең, хокук саклау органнары хезмәткәрләренең кайбер категорияләренә һәм аларның гаилә әгъзаларына, шулай ук хәрби хезмәттән чыгарылган гражданнарның аерым категорияләренә медицина ярдәмен күрсәтүнең, шифаханә-курорт тәэминатының һәм аерым түләүләрне тормышка ашыруның тәртибе турында», 2011 елның 30 декабреннән № 1232 «Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының хезмәткәрләренә, эчке эшләр органнарында хезмәттән чыгарылган Россия Федерациясе гражданнарының аерым катергорияләренә һәм аларның гаилә әгъзаларына медицина ярдәмен күрсәтүнең һәм аларның шифаханә-курорт тәэминатының тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарларын һәм 2017 елның 29 декабреннән № 1084 «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең Дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының карарларын башкаруында, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының ведомствосы карамагында булган медицина оешмаларында хәрби хезмәткәрләргә, хәрби сборларга чакырылган гражданнарга, Дәүләт янгынга каршы хезмәте федераль янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-башкарма системасының, Россия Федерациясе таможня органнарының хезмәткәрләренә, Россия Федерациясе милли гвардиясенең гәскәрләрендә хезмәт узучы һәм полициянең махсус исемнәренә ия булучы шәхесләргә, һәм федераль фельдъегер элемтәсе органнарының башлыклар составының шәхесләренә, алар хәрби хезмәттә булуның чик яшенә җитү буенча, сәламәтлек хәлләре буенча яисә оештыру-штаттагы чаралары белән бәйле рәвештә хезмәттән чыгарылган, хәрби хезмәтнең гомуми дәвамлыгы льготалы исәпләүдә 20 ел һәм аннан артыграк тәшкил иткән,ә хәрби хезмәтнең гомуми дәвамлыгы 25 ел һәм аннан артыграк тәшкил иткәндә хәрби хезмәттән чыгару нигезләренә бәйлелектән тыш офицерларга, шулай ук хәрби хезмәтнең гомуми дәвамлыгы 20 ел һәм аннан артыграк тәшкил иткән, алар хәрби хезмәттә булуның чик яшенә җитү буенча, сәламәтлек хәлләре буенча яисә оештыру-штаттагы чаралары белән бәйле

рәвештә хезмәттән чыгарылган прапорщикларга һәм мичманнарга, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә (түбәндә – хәрби һәм аңа тиңләштерелгән хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле махсус исеменә ия булучы гражданнарның аерым категорияләренә) 2017 елның 22 декабреннән 2018 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасы буенча медицина ярдәме өчен түләү турында Тариф килешүе (түбәндә – 2018 елга Тариф килешүе) белән расланган тарифларга туры китереп, медицина ярдәмен күрсәтү мизгелендә гамәлдәге тарифлар буенча медицина ярдәмен күрсәтергә, дип билгеләргә.

2. 2018 елның 1 гыйнварына кадәр тәүлек буе эшли торган һәм көндезге стационарларга кергән, ә 2018 елда шул стационарлардан чыккан, хәрби һәм аңа тиңләштерелгән хезмәт вазыйфаларын башкару уңае белән махсус исеменә ия булучы гражданнарның аерым категорияләренә күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләү 2018 елның 1 гыйнварыннан гамәлдәге тарифларга туры китереп үткәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләренең җитәкчеләренә 2018 елның 1 гыйнварынан башлап тәүлек буе эшли торган стационарларга һәм көндезге стационарларга кергән, амбулатор-сырхауханә ярдәме өчен мөрәҗәгать иткән хәрби һәм аңа тиңләштерелгән хезмәт вазыйфаларын башкару уңае белән махсус исеменә ия булучы гражданнарның аерым категорияләренә күрсәтелгән медицина ярдәме өчен счёт-реестрларның яңадан исәпләвен 2018 елга Тариф килешүе буенча тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары А.Д.Гариповка йөкләргә.

Министр М.Н.Садыйков